ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2022 г. Казань № 724-259/тп-2022

2023 елга «Коркачык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән ташландык су агызу системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу кагыйдәләрен раслау һәм кайбер Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мөрәҗәгать итүчеләрнең су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтырган (технологик ялгаган) өчен индивидуаль тәртиптә түләү билгеләнә торган объектларының тоташтырыла (ялгана) торган йөкләнеш зурлыгын билгеләү турында» 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Коркачык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән ташландык су агызу системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен шушы карар кушымтасына туры китереп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2022 № 724-259/тп-2022
карарына кушымта

«Коркачык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән ташландык су агызу системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар

| Т/с | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыру өчен тарифлар (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның база ставкасы | мең сум/тәүлегенә куб.метр | 1,0592* |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/км | 4 280,46 |
| 3. | Челтәрләрнең диаметрына карап, тарифны дифференциацияләү коэффициенты: | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм азрак | - | - |
| 3.2. | диаметры 40 мм югары, 70 мм кадәр | - | - |
| 3.3. | диаметры 70 мм югары, 100 мм кадәр | - | - |
| 3.4. | диаметры 100 мм югары, 150 мм кадәр | - | 0,50 |
| 3.5. | диаметры 150 мм югары, 200 мм кадәр | - | 0,51 |
| 3.6. | диаметры 200 мм югары, 250 мм кадәр | - | 0,55 |
| 3.7. | диаметры 250 мм һәм аннан да югары | - | - |

Искәрмә: * «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясының 13 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге